Республика Татарстан
Глава Старо-Мавринского сельского поселения Заинского муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Иске Маврин авыл җирлеге башлыгы

ул. Центральная, д. 2а, с. Старое Маврино, Заинский район, 423537

Үзәк урамы, 2а йорт, Иске Маврин авылы, Зәй районы, 423537

Телефон, факс 62-0-01. Электронный адрес: Smavr.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

**13.11.2018 ел** **№1**

**«2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына һәм Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

## карар бирәм:

1. «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 20 ноябрендә иртәнге сәгать 10.00 дә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Иске Маврин авылы, Үзәк урамы, 4 а йорты.

2. Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Горбунова С.Г.:

- ачык тыңлаулар үткәрүне оештырырга;
- әлеге карарны, ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча беркетмәне Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга, шулай ук җирлекнең мәгълүмати стендларына эләргә;
- «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карар проектын Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең рәсми сайтында, авыл җирлегенең мәгълүмат

стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (кушымта).

3. «2019 елга һәм 2020 - 2021 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карар проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр язмача формада түбәндәге адреска җибәрелә: 423537, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Иске Маврин авылы, Үзәк урамы, 2 а йорты (конвертта «бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән).

4. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә, утырышта яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын Зәй муниципаль районы Иске Маврин к авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл башлыгы урынбасары Е.С.Мишановка йөкләргә.

**Авыл җирлеге башлыгы** **В.М.Михайлова**